**ДӘВЕРЛӘРНЕ АЧАР АЧКЫЧЫМ БАР – РӘХМӘТ ЯУСЫН ТУГАН ТЕЛЕМӘ!**

# “Күкнең җиденче катында”

**“Күп профильле 181 нче мәктәп”**
**Ноябрь, 2019 нчы ел.**

Газетабызның өченче саны,
Төкле аягың белән!
Мәктәбебез тормышына
Өстәп тор син ямь!



**БУ САНДА:**

Мәктәп яңалыклары.
Әниләр көне белән!
Безнең җиңүләр
Бәйрәмнәр

## Мәктәп яңалыклары...

Менә көзнең соңгы аена да аяк бастык. Пыскып кына көзге вак яңгыр сибәли... Ә яңа, якты мәктәбебездә көндәлек тормыш кайный: төрле күңелле чаралар, бәйге-конкурслар, кичәләр гел үткәрелеп тора.

Зур әзерлек белән оештырылган бу чаралардан укучылар шатланып кайтып китәләр. Башлангыч, югары сыйныфлар тарафыннан әзерләнгән “Көзге марафон” әнә шулай күңелле үтте!





# Әниләр көне белән!

**Әни – кеше тормышындагы иң мөһим һәм кадерле кеше. Әниләргә багышлап күпме шигырьләр язылган да, күпме җырлар җырланган... Тик гел яңалары туа тора, чөнки әни кешегә күпме генә матур, җылы сүзләр әйтсәң дә аз булачак һәм хисләрне аңлатырга җитмәчәк...**





Әнием! Әнием! Әнием!
Таң нурыдай назлы кулларың
Әнием тик сиңа багышлап
Җырлыйлар яраткан кызларың...

Безнең мәктәбебездә “Әниләр бәйрәме” аеруча матур булды! Бар сыйныф бәйрәмгә тырышып әзерләнде. Әниләребезгә иң изге теләкләр яңгырады, шигырьләр сөйләнеп, җыр – биюләр багышланды. Һәр сыйныф кул эшләре, матур рәсемнәре белән әниләрен сөендерде! Никадәр ихласлылык җылытты ул кичәне: күңелдән нур булып ярып чыккан котлау сүзләре, шатлыктан күз читләрен чылаткан кайнар яшьләр, тыеп калып булмый торган хисләр ташкыны... Җырларның һәр нотасы да, биюләрнең иң гади хәрәкәтләре дә, шигырьләрнең һәр рифмасы да, һәрберебезнең үз әнисенә карап алган күз карашы да – барысы да күңел түренә үтеп кереп онытылмаслык хатирәгә әверелде.

# Безнең җиңүләр






**Үзләре өлгер, үзләре тырыш, акыллы да соң безнең укучыларыбыз. Төрле бәйгеләрдә катнашып, югары дәрәҗәдәге урыннарга лаек булдылар. Афәрин!**



“Чиксез балачак” халыкара фестивалендә җиңүчеләрне (Вилданова Диләрә (6Б), Корчагина Яна (9А), Морозова Марья (7Г), Мингареева Рината (5Д) уңышлары белән тәбриклибез! Афәрин!



9 нчы сыйныф укучылары – Корчагина Яна “Әниләргә багышлап...” (“Посвящение маме»), Нургалиева Җәмилә “Туган телләрне саклау һәм өйрәнү” бәйгесендә катнашып, 2 нче урынны яулап, диплом белән бүләкләнделәр. Җәмиләне, Янаны чын күңелдән котлыйбыз, яңадан-яңа уңышлар телибез!

Бөтен Рәсәй олимпиадаларының муниципаль этабында математика фәненнән призер укучыларыбыз Сивков Роман (4А), Грабалова Оксана (6Д), Демьянов Романны (6Д) лаеклы җиңүләре белән котлыйбыз. Киләчәктә дә югары үрләр яулауларын телибез.

4 нче ноябрь **“Халыклар бердәмлеге”** көне. Бердәмлек төшенчәсе - туплану, берләшү мәгънәсенә ия. Халкыбызга элек-электән хас сыйфат бу. Бердәмлек,татаулык күп кенә авырлыкларны җиңеп чыгарга ярдәм иткән, илебезнең тынычлыгына, мөстәкыйльлегенә китергән. Халыклар бердәмлеге безне бердәм булырга, ата-бабаларыбызның каһарманлыгын хөрмәт итәргә өйрәтә.

1612 нче елгы тарихи вакыйгалар...

Бу көннәрдә безнең ата-бабаларыбыз - төрле милләт, дин, катлам вәкилләре - бер булып, уртак Ватаныбызны чит илбасарлардан азат иткән. Төрле милләт кешеләренең иң югары максатларга ирешү өчен берләшүе, Ватанга карата чиксез мәхәббәте һәм ватанпәрвәрлеге илебезгә тарих сынауларын җиңеп чыгарга ярдәм иткән.

16 ноябрь - **Халыкара толерантлык көне**. Әлеге төшенчә барлык кешегә дә таныш булмаска мөмкин. Тик аның мәгънәсе кешелек җәмгыятенең үсеше өчен бик әһәмиятле булып тора. Заманча мәдәниятле кеше — ул укымышлы гына түгел, ә башкалар тарафыннан хөрмәткә ия һәм үз-үзен ихтирам итүче кеше дә.

Нәрсә соң ул толерантлык? Фәлсәфи энциклопедиядә бу сүзгә түбәндәге аңлатма бирелгән: толерантлык (латинча tolerantia — түземлелек) — икенче, башка төрле карашларга, холыкка, гореф-гадәтләргә түзем-лелек. Ә чит телләр сүзлегендә “толерантлык – чит фикерләргә һәм чит диннәргә карата түземлелек” дип бирелә. Бүген Җирдә 3 мең төрле милләт вәкиле яши. Русия Федерациясе — иң зур күпмилләтле ил, илебездә 166 милләт исәпләнә. Үткә-небез, бүгенгебез, киләчәгебез) — һәркайсы Ватаныбызның язмышы белән тыгыз бәйләнгән. Туган илебезнең азатлыгы һәм бәйсезлеге хакына халыкларның берләшүе, бөек, иҗади максатлар тирәли туплануы җәһатеннән Русия һәрчак көчле булды. Туган илгә сөю, милли тарихка, ата-бабалары-бызның хәрби каһарманлыгына, хезмәт казанышларына ихтирам кебек мәңгелек кыйммәтләр гасырлардан-гасырларга тапшырылып килә. Мондый күчәкилүчәнлек — дәүләтчелегебезнең ныклы таянычы, ил алдында торган мөһим, әһәмиятле бурычларны үтәүдә уңышка ирешергә булышлык итә.

Республикадагы иминлек ул — милләтләрнең килешеп яшәвенең күркәм бер үрнәге.

**Редакциянең адресы:**
420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576

**Тираж** – 50 экз..
**Баш мөхәррир һәм дизайнер:** Габдуллаҗанова А.Ф..
**Редколлегия әгъзалары:** Мәхмүтова Мәдинә, Абрамова Дарья, Вәлиева Диләрә, Мельникова Аделина, Мәхмүтова Мәликә, Корчагина Яна.